Балалар өчен Изге Язма

тәкъдим итә



# Нух һәм Бөек туфан

Автор: Edward Hughes
Рәсемнәр: Byron Unger; Lazarus
Alastair Paterson
Кемнәр өчен: M. Maillot; Tammy S.
Тәрҗемә ителде: www.christian-translation.com
Гамәлгә ашырылды: Bible for Children
www.M1914.org

BFC
PO Box 3
Winnipeg, MB R3C 2G1
Canada

©2020 Bible for Children, Inc.
Лицензия: Сезнең бу хикәят текстын, сату хокукыннан башка гына, күчермә итеп яки бастырып алу хокукыгыз бар.



Нух Аллаһыга иман китереп яши торган диндар кеше була. Башкалар Аллаһыны күрә алмый һәм аның әмерләрен үтәми. Бервакыт Аллаһы: “Бөтен кешелек дөньясын юк итәчәкмен! Бары тик синең гаиләң генә котылып калыр”, - дип әйтә.




Аллаһы Нухка Җир йөзендә бик зур туфан булачагы, су басачагы турында кисәтә. – Гаиләң өчен дә, күп кенә хайваннар өчен дә сыйдырышлы көймә төзе, - дип боера. Аллаһы Нухка төгәл күрсәтмәләр бирә. Нух кичекмәстән көймә төзергә керешә!
3
Нухның ни өчен көймә төзегәнлеген белгән кешеләр, мөгаен, аннан көлә генә. Ә Нух эшен дәвам итә. Ул аларга Раббы Алла турында сөйләвеннән дә туктамый. Ләкин аны беркем дә тыңларга теләми.
4
Нухның бик нык дингә ышана. Ул, моңарчы андый туфан яңгырлары яумаса да, Аллаһы әйткән сүзләргә ышана. Тиздән көймә үзенең булачак хуҗалары өчен төзелеп бетә.
5
Хайваннар чираты килеп җитә. Аллаһы бер токымга караган җиде пар, һәм башка токымга караганнарын икешәр пар итеп китерә. Зур һәм кечкенә кошлар, вак һәм эре хайваннар көймәгә төялә.
6
Хайваннарны көймәгә утырткан вакытта кешеләр Нухка нинди генә сүзләр әйтеп мыскылламый. Аллаһы сүзенә каршы килеп, гөнаһ кылудан туктамыйлар. Көймәгә утырт әле, дип тә ялынмыйлар.
7
Ниһаять, көймәгә утырасы хайваннар һәм кошлар җыелып бетә. Аллаһы Нухка: “Үзең дә, гаиләң дә көймәгә утырыгыз”, - дип боера. Нух, аның хатыны, өч улы һәм киленнәре көймәгә керә. Шуннан Аллаһы көймәнең ишеген ябып куя!
8


Шуннан яңгыр ява башлый. Көчле яңгыр аркасында Җир йөзен су баса, су күтәрелү кырык көн, кырык төн дәвам итә.
9
Шәһәрләр һәм авыллар су астында кала. Яңгыр туктаганда биек-биек таулар да су астында калган була. Җир йөзендәге сулышы булган һәр тереклек иясе һәлак була.
10
Су ташкыны арта барган саен, көймә су өстеннән йөзүен дәвам итә. Мөгаен, көймә эчендә тома караңгы, хәтта ки, каты давыл булып, бик куркыныч та булгандыр. Әмма бу көймә Нухны су басудан саклап тора.
11
Биш айга сузылган су басудан соң Раббы Алла коры җил истереп җибәрә. Көймә акрын гына Арарат таулары түбәсенә менеп утыра. Су кимеп беткәнчегә кадәр, әле тагын кырык көн дәвамында Нух көймә эчендә кала.
12
Нух ачык көймә тәрәзәсеннән бер карга белән күгәрченне очыртып җибәрә. Ял итү өчен коры урын таба алмыйча, күгәрчен Нух янына кире әйләнеп кайта.
13
Бер атна узгач, Нух янә күгәрченне очыртып җибәрә. Күгәрчен томшыгына яңа зәйтүн яфрагы кыстырып кайтып керә. Киләсе атнада Нух Җирнең инде кипкән булуын белә, чөнки күгәрчен очып киткән җиреннән әйләнеп кайтмый.
14













Нух һәм Бөек туфан

Аллаһы Сүзеннән, Изге Язмадан хикәят

урнашкан

Яратылыш 6-10

“Сүзләреңнең күренүе балаларны яктыртып
акыллыландыра.” Мәдхия 119:130

19

# Тәмам

3

60

20

Әлеге Изге Язма хикәятендә Җир йөзендәге барча тереклекне бар кылган һәм Үзенә иман китерүебезне теләгән кодрәтле Аллаһы турында бәян ителә.

Раббыбыз начар гамәлләр кылуыбыз турында белеп тора, Ул аларны гөнаһ дип атый. Гөнаһның җәзасы – үлем. Ләкин Аллаһы сезне шулкадәр ярата ки, гөнаһларыгыз өчен җәзаланырга дип бердәнбер Улы Гайсәне хачта үтертү өчен җибәрде. Шуннан соң Гайсә үлеп терелде һәм Күккә ашты! Гайсәгә ышансагыз, гөнаһларыгызны кичерүе турында сорагыз, Ул моны эшләр! Ул килер һәм сездә яшәр, һәм сез дә мәңге Аның белән бергә булырсыз.

Моның хак булуына ышансагыз, Аллаһыга болай диегез: Хөрмәтле Гайсә, Синең Раббы булуыңа һәм гөнаһларым хакына һәлак ителү өчен кеше булып яралтылуыңа һәм хәзерге вакытта исән булуыңа ышанамын. Зинһар өчен, тормышыма үтеп кер, мин яңа тормыш башлап, кайчан да булса Синең белән мәңге бергә була алсын өчен, гөнаһларымны ярлыка. Балаң күк, Сиңа сәҗдә кылып, Сиңа иман китереп яшәргә ярдәм ит. Амин.

Изге Язма укы һәм көн саен Аллаһы юлында бул! (Яхъя 3:16)